Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Чистай авылы җирлегенең Луч авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай авыл җирлеге составына керүче Луч авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында

КАРАР

2019 елның 23 ноябре № 02

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 14,16,19,23 ноябрләрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Чистай авыл җирлегенең Луч авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- зират коймасы;
- территорияне төзекләндерү - Гагарин урамы буйлап тротуар юлы салу

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 952 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 560 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 539 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 21 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Чистай авыл җирлегенең Луч авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы Чистай авыл җирлегенең Луч авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- зират коймасы;
- территорияне төзекләндерү - Гагарин урамы буйлап тротуар юлы салу буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Чистай муниципаль районы Чистай авыл җирлегенең Луч авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Чистай авыл җирлегенең Луч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы

гаиләләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- зират коймасы;
- территорияне төзекләндерү - Гагарин урамы буйлап тротуар юлы салу.

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чистай авыл җирлеге башлыгы _________________ Р.М.Мәгъсүмов